**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**ул.Ленина, д.60,**
**с. Старый Мензелябаш, 423354**
**Телефон: (85559) 4-53-46**
**E-mail: Smnz.Sar@tatar.ru**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**Ленин урамы, 60 йорт,**
**Иске Минзәләбаш авылы, 423354**
**Телефон: (85559) 4-53-46**
**E-mail: Smnz.Sar@tatar.ru**

***ОКПО 93068290, ОГРН 1061687002442, ИНН/ КПП 1636005422/ 163601001***

---

КАРАР

18.05.2015 ел № 3

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты каршында
Балигъ булмаганнар эшләре буенча
иҗтимагый комиссия булдыру турында

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июненең 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян салуны кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябренең 71-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә һәм балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм алар арасында хокук бозуларны кисәтү, социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр белән профилактик эш алып бару максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты каршында Балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссия турында” нигезләмәне расларга (1нче кушымта).
2. Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты каршында Балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссиянең составын расларга (2нче кушымта).
3. Әлеге карарны Иске Минзәләбаш авылы, Ленин урамы, 58нче йорт, Куҗак авылы, Совет урамы, 64нче йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
4. Карарның үтәлешен контрольгә алуны үз өстемә алам.

Иске Минзәләбаш
авыл җирлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе А.Р. Мияссәрова

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2015 елның
18 маеннан 3нче номерлы карарына
1нче кушымта

# ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРШЫНДА БАЛИГЪ БУЛМАГАННАР ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ИҖТИМАГЫЙ КОМИССИЯ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссия (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасы Сарман районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегендә балигъ булмаганнарның хокуларын яклау, күзәтүчесезлеген һәм алар арасында хокук бозуларны кисәтү системасының коллегиаль органы булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Россия Федерациясе хөкүмәтенең норматив актларына, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив хокукый актларына, Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хокукый актларына һәм Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты каршында балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссия турында нигезләмәгә таянып эш итә (алга таба - Нигезләмә).

3. Комиссия эшчәнлеге законлылык, демократизм, балигъ булмаганнарга карата шәфкатьлелек, гаиләгә ярдәм итү һәм тыгыз бәйләнештә булу, балигъ булмаганнарга индивидуаль караш, билгеле булган мәгълүматны конфеденциальлеген саклау, балигъ булмаганнарның хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен бозган өчен вазифаи затларның һәм гражданнарның җаваплылыгын тәэмин итү принципларына нигезләнә.

4. Әлеге Нигезләмәдәге төшенчәләр «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июненнән 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян салуны кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябреннән 71-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы билгеләгән мәгънәдә кулланылды.

Әлеге Нигезләмә максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:
**балалар (балигъ булмаган)** – 18 яше тулмаган затлар, эмансипацияләнгән балигъ булмаганнардан һәм 18 яшькә җиткәнче никахлашкан затлардан тыш;
**күзәтүчесез -** ата-аналар яисә балигъ булмаганнарның башка законлы вәкилләре, яки вазифаи затлар тарафыннан тәрбияләү, укыту һәм (яки) карап тоту бурычларын үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү аркасында тәртибе контрольдә тотылмаучы балигъ булмаган бала;
**караучысыз (урам баласы)** – яшәү урыны булмаган **күзәтүчесез** балигъ булмаган бала;

**социаль куркыныч хәлдә калган балигъ булмаган бала -** күзәтүчесез, караучысыз калу сәбәпле тормышына, сәламәтлегенә куркыныч янаган яки баланы тәрбияләү, карап тоту таләпләренә туры килми торган хәлдә калган яисә хокук бозу, җәмгыятькә каршы гамәлләр кылучы зат ;

**социаль куркыныч хәлдә калган гаилә** - социаль куркыныч хәлдә калган балалары булган гаилә, һәм шулай ук ата-аналар яисә балигъ булмаганнарның башка законлы вәкилләре аларны тәрбияләү, укыту һәм (яки) карап тоту буенча бурычларын үтәмәгән һәм (яки) аларның тәртибенә кире йогынты ясаучы яки балаларга карата рәхимсез мөгамәләдә булган гаилә;

**гаилә иминсезлегенең башлангыч сталиясендә булган гаилә** – гаиләнең бар әгъзаләренең тормышы һәм тиешле үсешен тәэмин итүгә уңай шартлар тудыруда мөмкинлекләрен чикләүче проблемалары булган гаилә;

**балаларга карата рәхимсезлек** – физик, психик, сексуаль көч куллануның барлык формалары, ата-аналар яки балигъ булмаганнарның башка законлы вәкилләре тарафыннан кылынган яки үзвакытында кылынмаган гамәлләр нәтиҗәсендә баланың сәламәтлегенә, үсешенә һәм (яки) абруена зыян китерүдә чагылган **бала** ихтыяҗларын санга сукмау;

**индивидуаль профилактик эш** – социаль куркыныч хәлдә калган балигъ булмаганарны һәм гаиләләрне үзвакытында ачыклау, шулай ук аларга социаль-педагогик реабилитация үткәрү һәм (яки) алар тарафыннан хокук бозу һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуны кисәтү буенча эшчәнлек;

**җирлек** – шәһәр яки авыл җирлеге;

**күзүтүчесезлек һәм балигъ булмаганнар тарафыннан хокук бозуларны кисәтү** – балигъ булмаганнар һәм социаль куркыныч хәлдә калган гаиләләр белән индивидуаль профилактик эш үткәрү белән берлектә алып барылучы күзәтүчесезлеккә, караучысызлыкка, балигъ булмаганнарның хокук бозуларына, җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуына китерү сәбәпләрен һәм шартларын ачыклау һәм юк итүгә юнәлдерелгән социаль, хокукый, педагогик һәм башка чаралар системасы;

**балигъ булмаган балаларга керү катгый тыелган урыннар -** Федераль закон белән билгеләнгән һәм (яки) бу закон нигезендә билгеләнгән анда булу балаларның сәламәтлегенә, физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерергә мөмкин урыннар;

**балигъ булмаган балалар булу чикләнгән урыннар -** Федераль законда билгеләнгән һәм (яисә) әлеге закон нигезендә билгеләнгән, балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү максатларында, балигъ булмаганнарның ата-аналары (аларны алмаштыручы затлар), шулай ук балалар катнашында чаралар үткәрүче затлар озатуыннан башка төнге сәгатьләрдә балигъ булмаган балаларның булуы тыелган урыннар;

**Ата-ананы алмаштыручы затлар -** законные представители несовершеннолетнего, а также совершеннолетние родственники и иные лица, сопровождающие несовершеннолетнего с согласия или по поручению его родителей (законных представителей), выраженного в устной или письменной форме;

балигъ булмаган баланың законлы вәкилләре, шулай ук аның әти-әнисе (законлы

вәкиле) ризалыгы белән яки аларның телдән яисә язма рәвештә белдерелгән кушуы буенча озатып баручы балигъ булган туганнары һәм башка затлар;
**төнге сәгать** – 1нче сентябрьдән алып 31нче майны кертеп 22.00-6.00 сәгатьләр арасындагы вакыт яки 1нче июньнән алып 31 августны кертеп 23.00-6.00 сәгатьләр арасындагы вакыт.

5. Комиссия җирлнек Уставына нигезләнеп төзелә.
6. Комиссия каралган сораулар буенча карарлар кабул итә.
7. Комиссия үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе (алага таба - Район комиссиясе) белән тыгыз элемтәдә алып бара.

II. Комиссиянең максаты һәм төп бурычлары

8. Комиссия җирлектә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, хокук бозуларын кисәтү эшендә, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм гаиләләр белән шәхси профилактик эш алып баруда район комиссиясенә ярдәм итү максатыннан оештырыла.

9.Комиссиянең төп бурычлары:
1) балигъ булмаганнарны тәрбияләү, укыту һәм (яки) карап тоту буенча бурычларын үтәмәгән һәм (яки) аларның тәртибенә кире йогынты ясаучы яки балаларга карата рәхимсез мөгамәләдә булган ата-аналарны яки башка законлы вәкилләрен ачыклау;
2) җирлектә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны, алкоголизмны, наркоманияне һәм башка тискәре күренешләрне кисәтү;
3) җирлектә балаларга карата рәхимсез мөгамәлә фактларын ачыклау һәм кисәтү;
4)балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эшен оештыруда район комиссиясенә ярдәм күрсәтү
5) Җирлектәге балаларның хәленә кагылышлы мәсьәләләр буенча район комиссиясенә мәгълүмат бирү.

III. Комиссиянең вәкаләтләре.

10. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне башкара:
1) җирлектә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау буенча чаралар оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;
2) балалар өчен тыелган урыннарда, шулай ук төнлә ата-аналар яки бүтән законлы вәкилләр озатмыйча, балаларга бару тыелган урыннарда балаларның булуын ачыклау рейдларында катнаша;
3) күзәтүчесез, караучысыз балаларны, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне, шулай ук даими рәвештә дәрес калдыручы балигъ булмаганнарны ачыклау буенча рейдлар үткәрүдә катнаша;
4) балигъ булмаганнарга алкогольле продукция һәм тәмәке әйберләре сату очракларын ачыклау буенча рейдларда катнаша;

5) балигъ булмаганнарның яшәү урыны буенча ялын оештыруны, гомуми белем бирү, мәдәни-агарту учреждениеләрендә, башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләрендә балигъ булмаганнар белән тәрбия-профилактика эшенең торышын контрольдә тота;
6) үз утырышларында балаларны тәрбияләү белән шөгыльләнмәгән ата-аналарны яки башка законлы вәкилләрне, шулай ук сукбайлыкка тартылучы, мәгариф учреждениеләрендә даими рәвештә дәрес калдыручы балигъ булмаганнарны тыңлый;
7) балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу очраклары турында район комиссиясенә хәбәр итә;
8) шундый очраклар ачыкланганда, “Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм балигъ булмаганнарны Исәпкә алу һәм мониторинглау” мәгълүмат системасының “сигнал картасын " тутыра;
9)район комиссиясенең йөкләмәләрен үти;
10)балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау мәсьәләләре буенча иҗтимагый, дини оешмалар, партияләр, хәрәкәтләр, педагоглар һәм ата-аналар коллективлары белән хезмәттәшлек итә һәм үз эшенә җәлеп итә.

## IV. Комиссиянең төзелү тәртибе

11Комиссия җирлек башлыгы карары белән төзелә.
12. Комиссиянең эшчәнлеге җәмәгать башлангычында алып барыла.
13. Комиссиянең нигезләмәсен, комиссиядәге кеше санын, шәхси составын җирлек башлыгы раслый.
14. Комиссия составына комиссия рәисе – җирлек башлыгы, комиссия сәркатибе һәм башка әгъзалары керә.
15. Комиссия составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, җирлек депутатлары, представители органов местного самоуправления, депутаты Думы поселения, мәгариф, мәдәни-агарту учреждениеләре, сәламәтлек саклау учреждениеләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләре, эчке эшләр органнары хезмәткәрләре, ата-аналар комитетлары әгъзалары һәм балигъ булмаганнар белән эшләү тәҗрибәсе булган башка гражданнар.1
16.Комиссия составы 5 кешедән ким булмаска тиеш.

## V. Организация работы ОКДН

17. Комиссия җирлек территориясендә түбәндәге балигъ булмаганнарга карата индивидуаль профилактик чараларны үткәрүдә район комиссиясенә ярдәм күрсәтә:
1) иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәннәр; шартлы рәвештә яки иректән мәхрүм ителү белән бәйле булмаган җәза чараларына хөкем ителгәннәр; җәмәгать яисә административ йогынты чаралары куллану сәбәпле яисә амнистия аркасында җинаять җаваплылыгыннан азат ителгәннәр; җинаять җаваплылыгына тартылучылар; җинаять җаваплылыгы билгеләнә торган яшькә җиткәнче җәмгыяви куркыныч гамәлләр кылган; ябык типтагы махсус гомуми белем бирүче учреңдениеләрдән кайткан (махсус мәктәп, ПТУ);

2 административ хокук бозулар кылучы, системалы рәвештә спиртлы эчемлекләр, наркотик һәм агулы матдәләр кулланучы;
3) 16 яшькә кадәр гаиләдән үз белдеге белән китүчеләр яки махсус укыту-тәрбия учреждениеләреннән китүчеләр;
4) хокук бозулар кылган, ләкин җинаять яки административ закон нормаларына эләкмәгән балигъ булмаганнар;
5) системалы рәвештә мәгариф учреждениеләрендә дәрес калдыручылар;
6) атаның (ананың) РФ Җинаять кодексының 82нче маддәсе тәртибендә җәза үтүен кичектергән гаиләләрдә тәрбияләнүче;
7) балаларга бару өчен тыелган урыннарда, шулай ук төнлә балаларга бару тыелган урыннарда ачыкланган.

18. Үзенең утырышларында тыңлый:
1) балигъ булмаган балаларны тәрбияләү, карап тору бурычларын үтәмәгән һәм (яки) аларның тәртибенә тискәре йогынты ясаучы, яки аларга карата рәхимсез мөгамәлә итүче ата-аналар яисә башка законлы вәкилләрне;
2) нигезләмәнең 17нче пунктында санап үтелгән балигъ булмаганнарның әти-әниләрен родителей яисә башка законлы вәкилләрен;
19. Район комиссиясенә тәгъдимнәр кетә:
1) балигъ булмаганнарның җәйге ялын һәм ялын оештыру буенча;
2) балигъ булмаганнар белән шәхси профилактик эш алып бару буенча;
3) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлегенә һәм җәмгыяви тискәре тәртибенә китерүче сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча.
20. Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләргә рейдлар оештыра һәм үткәрә.
21. Район комиссиясенә тапшыру өчен социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне тикшерү актларын төзи.
22. Җинаять-башкарма инспекцияләре тарафыннан җәмгыятьтән аермыйча гына хөкем ителгән балигъ булмаганнарны, шулай ук РФ Җинаять кодексының 82нче маддәсе тәртибендә яшәгән урыннары һәм җәмәгать урыннарында җәза үтәүне кичектереп торып хөкем ителгән балигъ булмаганнарны тикшерү буенча оештырылган рейдларда катнаша.
23. Нигезләмәнең 17 нче пунктында күрсәтелгән балигъ булмаганнар гаиләләренең һәм гаилә иминсезлегенең башлангыч стадиясендә булган гаиләләрнең социаль паспортларын алып бара.
24. Балигъ булмаганнар һәм ата-аналар яки башка законлы вәкилләр арасында хокукый белемнәрне пропагандалау эшендә катнаша.
25. Җирлек халкы белән мәгълүмати - аңлату эшләре алып бара (ачык агитация, ММЧ).

## VI. Комиссиянең эшчәнлеге тәртибе.

26. Комиссия эшчәнлеге бер елга планлаштырыла.
27. Комиссия рәисе тарафыннан расланган еллык эш планы район комиссиясенә җибәрелә.
28. Комиссия утырышлары кирәк булганча үткәрелә, ләкин айга ким дигәндә бер тапкыр.

29. Утырышларга комиссия әгъзалары булмаган башка затлар да чакырылырга мөмкин.
30. Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларның гомуми саныннан кимендә яртысы булса, хокуклы санала. Комиссиядә карала торган мәсьәләләр буенча карар комиссия әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Әгәр комисия әгъзасы, комиссия карары белән килешмәсә, комиссия карарына язмача аерым фикер кертергә хокуклы.
31. Комиссия утырышының көн тәртибе, утырыш башланырга 3 көннән дә соңга калмыйча, рәис тарафыннан билгеләнә. Комиссия утырышының көн тәртибендә күрсәтелергә тиеш:
1) сорауның тәртип буенча номеры;
2) сорауның исеме;
3) сорау кем тарафыннан кертелгән.
32. Комиссия әгъзалары комиссия утырышында катнашырга тиеш. Нигезле сәбәпләр аркасында комиссия утырышында катнаша алмау турында комиссия әгъзасы, юклыкның сәбәбен күрсәтеп, комиссия рәисенә алдан хәбәр итә.
33.Утырышны комисия рәисе үткәрә.
34.Комиссия утырышы беркетмәсе утырыш вакытында ясалган язмалар (стенограмма), докладларның һәм чыгышларның әзерләнгән тезислары, белешмәләр һәм башка материаллар нигезендә төзелә.
35.Комиссия утырышлары вакытында язулар, материаллар җыю һәм протокол текстын әзерләү комиссия секретаренә йөкләнә.
36.Беркетмәдә күрсәтелергә тиеш:
1) утырышны үткәрү датасы һәм урыны;
2) комиссия әгъзаларының составы, чакырылган затлар;
3) карала торган материалларның эчтәлеге;
4) комиссиядә каралучы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме; туган елы, ае, көне, туган урыны; эш яки уку урыны; материалларны карау өчен әһәмиятле булган башка мәгълүмат;
5) утырышта катнашучы затларның килүе турында, аларга аларның хокукларын һәм бурычларын аңлату турында белешмәләр;
6) утырышка килмәгән затларга билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителүе турында белешмәләр;
7) белешмәләр, чыгышлар, аналитик материаллар;
8) комиссия утырышында, үтәү һәм башкару сроклары өчен җаваплы затларны күрсәтеп, кабул ителгән карар турында белешмәләр.
37. Комиссия карарлары йомгаклаучы документ булып тора, язмача рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе тарафыннан имзалана.
38. Комиссия карарлары чаралар күрү өчен тиешле органнарга, учреждениеләргә, иҗтимагый оешмаларга җибәрелә.

VII. Комиссия рәисе, секретаре, башка әгъзаларының вәкаләтләре

39. Комиссия рәисе:
1) Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;

2) хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән комиссия утырышында катнаша;
3) комиссия әгъзаларының бурычларын билгели;
4) утырыш уздыру датасын билгели;
5) комиссия утырышының көн тәртибен раслый;
6) комиссия утырышында рәислек итә яки утырышны алып баруны комиссия әгъзасына йөкли;
7) комиссиянең эш планын раслый;
8) эш планының үтәлешен контрольдә тота;
9) комиссия утырышларында кабул ителгән карарларга кул куя;
10) әлеге Нигезләмәдә каралган башка мәсьәләләрне хәл итә.

40. Комиссия сәркатибе:
1) комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра;
2) хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән комиссия утырышында катнаша;
3) комиссиянең агымдагы эшен планлаштыруны, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау планнарын төзүне оештыра;
4) комиссиядә эш башкару алып бара;
5) комиссия эшчәнлеге һәм җирлектә яшәүче балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча органнар, учреждениеләр, иҗтимагый оешмалар белән мәгълүмат алмашуны оештыра;
6) башкарылган эш нәтиҗәләре турында район комиссиясенә ай саен мәгълүмат бирүне тәэмин итә;
7) комиссия карамагындагы территориядә үткәрелә торган район комиссиясенең җаваплы сәркатибенә ярдәм итә:
7.1) комиссия әгъзаларына утырыш датасы, карала торган мәсьәләләр турында хәбәр итә;
7.2) карала торган мәсьәләләр буенча гражданнарның чакырылуын тәэмин итә;
8) социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне ачыклау, караучысызлыкның, балигъ булмаганнарның хокук бозуларының сәбәпләрен һәм шартларын ачыклау буенча оператив эш оештыра;
9) Комиссия кабул иткән карарларның үтәлешен контрольдә тота.

41. Комиссия әгъзалары:
1 ) комиссия рәисе йөкләмәләрен үтиләр;
2) комиссия утырышларының көн тәртибенә мәсьәләләр кертү буенча үз тәкъдимнәрен кертәләр;
3) хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән комиссия утырышында катнашалар;
4) балигъ булмаганнар эшләре буенча инспектор, әлеге административ участокка беркетелгән участок уполномоченные белән берлектә җирлектә профилактик чаралар оештыруда һәм үткәрүдә катнашалар; балаларга йөрү тыелган урыннарда, шулай ук төнлә ата-аналар яки башка законлы вәкилләр озатуыннан башка балалрга булу тыелган урыннарда балаларның булуын ачыклау буенча рейдларда катнашалар.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2015 елның
18 маеннан 3нче номерлы карарына
2нче кушымта

**Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты каршында**
**Балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе:<br>Иске Минзәләбаш авыл<br>җирлеге башлыгы | Мияссарова Альфинур Рәфәт кызы |
| Комиссия сәркатие:<br>Башкарма комитетның<br>баш белгече | Сафина Гөлфия Илһаметдин кызы |
| Комисся әгъзалары :<br>Иске Минзәләбаш ФАП мөдире | Фахретдинова Рәзинә Марс кызы |
| Иске Минзәләбаш мәктәбе<br>директоры тәрбия эшләре<br>буенча урынбасары | Зарипова Гөлнара Марат кызы |
| Иске Минзәләбаш ветераннар<br>советы рәисе | Мөхәмәтҗанов Ленар Әмирҗан улы |
| Иске Минзәләбаш китапханәсе<br>китапханәчесе | Гарифуллина Айзирәк Әнәс кызы |
| Куҗак авылы ФАП мөдире | Әһлиева Гүзәлия Мизһәт кызы |
| Иске Минзәләбаш мәктәбенең<br>Башлангыч сыйныф укутычысы | Гыйльфанова Фәнүсә Мәгъсүмҗан кызы |
| Иске Минзәләбаш балалар<br>бакчасы мөдире | Габдрахманова Лилия Рамазан кызы |